# КҮПМЕ КҮЗЛӘР КҮРЕП ОНЫТЫЛГАН

*РИФГАТ ГОМӘРОВ музыкасы*
*ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ сүзләре*

Күпме күзләр күреп онытылган,
Күпме йөзләр чыккан исемнән,
Күпме сүзләр киткән хәтеремнән?! —
Ә син һаман, һаман исемдә.

Ничә тапкыр гүзәлләрне күреп,
Мин минутлык хискә исердем,
Айныдым да, сөенеп туялмыйча,
Тагын сине искә төшердем
.
Йөрәгемне, ахры. тутыргансың,
Башкаларга анда урын юк,
Күңелемдә синнән бүтәннәргә
«Сөям» дигән назлы жырым юк!